ГЛАВА
ЭБАЛАКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЯБАЛАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

10 нчы ноябрь 2021 ел Ябалак авылы № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Бәрлебаш авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 маддәләре,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Уставының 22маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 елның 24 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Бәрлебаш авылы,Вахитов урамы,2А йорт адресы буенча урнашкан Күпфункцияле үзәк бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегендә Бәрлебаш авылында **үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын** билгеләргә:
2. 2021 елның 26 ноябренә 09 сәгать 00 минутка Бәрлебаш төп гомуми белем бирү мәктәбе бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Бәрлебаш авылында **үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын** билгеләргә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Ябалак авыл җирлеге Бәрлебаш авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, урам утларын ремонтлау;
- җирлектәге торак пунктлардагы чүплекләрне чистарту;
- материаллар сатып алып чишмәне төзекләндерү;

*б)авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:*

- объект буенча проект-смета документациясен үтәү"Буаның гидротехник корылмасы буенча капиталь ремонт»

*в)организация в границах поселения водоснабжения населения:*

- материаллар сатып алып, суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау;

-су башнясын лицензияләү буенча түләү (су белән тәэмин итү чыганагының артскважинасын куллану өчен санитар-эпидемиологик бәяләмәне документаль рәсмиләштерү, су анализы һәм башка документлар)

*г) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

*д) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;*

- зиратларны чистарту һәм төзекләндерү, материаллар сатып алып контейнер мәйданчыкларын җиһазлау.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Ябалак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: https://ebalak-kaybici.tatarstan.ru

7. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Башкарма комитеты гражданнар җыенын үткәргәндә Ябалак авыл җирлеге территориясендә яңа коронавирус йогышы (GOVID-19) авыру очракларын кисәтү һәм таратуга каршы профилактик,санитар-эпедемик чараларының үтәлешен тәэмин итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы

Кайбыч муниципаль районы

Ябалак авыл җирлеге башлыгы Гыйзәтуллина М. Ф.